**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премиясен бирү комитеты турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премиясен гамәлгә кую турында» 2015 елның 3 июлендәге ПУ-619 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 4 июнендәге ПУ-503 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге ПУ-460 номерлы, 2018 елның 27 гыйнварындагы ПУ-109 номерлы, 2018 елның 17 ноябрендәге ПУ-778 номерлы, 2020 елның 21 июлендәге ПУ-432 номерлы, 2020 елның 25 ноябрендәге ПУ-778 номерлы, 2021 елның 21 июнендәге ПУ-503 номерлы, 2022 елның 8 июлендәге ПУ-470 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 19 июнендәге 412 номерлы һәм 2024 елның 8 июлендәге 522 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премиясе турында нигезләмәнең 2 пунктына, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Татарстан Республикасы Рәисе Указы нигезендә ел саен бирелә:

һәрберсе 500 мең сум күләмендә өч Премия – гражданнарга (гражданнар төркеменә);

һәрберсе 800 мең күләмендә биш Премия – оешмаларга.».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 07 август
№ 611